КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 9 апрель г.Казань № 383

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар – ярдәм алучылар республика реестры турында» 2012 ел, 16 март, 218 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар – ярдәм алучылар республика реестры турында» 2012 ел, 16 март, 218 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 сентябрь, 668 нче; 2015 ел, 5 июнь, 423 нче; 2023 ел, 13 июль, 828 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына:»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Республика башкарма хакимият органнарына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына – тәэмин итүне тәкъдим итәргә: әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында каралган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү турындагы мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген, шулай ук аларны Реестрга үз вакытында кертүне.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин